ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 485 от «15» 12 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 25 декабрендәге 469 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хокук бозуларны профилактикалауның күп дәрәҗәле системасын булдыру, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген ныгыту, күрсәтелгән эшчәнлеккә муниципаль органнарны, иҗтимагый формированиеләрне һәм халыкны җәлеп итү, җинаятьләр кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны локальләштерү максатларында, шулай ук «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 25 декабрендәге 469 номерлы карары белән расланган «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» Комплекслы программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 25 декабрендәге 469 номерлы карары белән расланган «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» Комплекслы программасының "2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру" программасы чаралары исемлегенәкушымта нигезендә 1.10- 1.15 пунктлар өстәргә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.М.Ефимов

Приложение к постановлению
Исполнительного комитета
Мамадышского муниципального
района Республики Татарстан
от 15.12. 2025 г № 485

| **1 нче бурыч. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе** | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.10. Балигъ булмаганнар өчен мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән һәм интернеттан файдаланып кылынган җинаятьләрне булдырмауга юнәлдерелгән чаралар үткәрү. | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге МКУ , Мәдәният бүлеге МКУ, Мәгариф бүлеге МКУ , Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча )) | 2025-2027 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.11. Компьютер технологияләрен кулланып, мошенниклык гамәлләренең иң киң таралган төрләре турында укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) балаларның мәгълүмати иминлеге чаралары турында мәгълүмат бирүне оештырырга. | Мәгариф бүлеге МКУ , ЗПК Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча )) | 2025-2027 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.12Халык арасында компьютер белемен пропагандалау максатында профилактик характердагы мәгълүмат белән искәрмәләр тарату. | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге МКУ ,, ММЧ | 2025-2027 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.13. Интернет челтәрен кулланучыларның мәгълүмати материалларны массакүләм | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге МКУ ,, ММЧ | 2025-2027 еллар | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән, шулай ук кибер куркынычлардан саклану ысуллары турында хәбәрдарлыгын арттыру. | | | | | | | | | | |
| 1.14. Интернет челтәрендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында төгәл күзаллау булдыру өчен профилактик чаралар үткәрү. | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге МКУ , Мәдәният бүлеге МКУ, Мәгариф бүлеге МКУ, ЗПК | 2025-2027 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.15. Хезмәт коллективларында мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр һәм Интернет кулланып кылынган җинаятьләрне булдырмауга юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү. | МКУ Отдел по делам молодежи и спорту, МКУ ОК; МКУ ОО, ОМВД (по согласованию) | 2025-2027 гг | | | | | | | | |